

ХЕЗМӘТ БАТЫР

ХЕЗМӘТ ТУРЫНДА ТАТАР ХАЛЫК МӘКАЛЬЛӘРЕ

КАЗАН • ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ • 1974



© Татарстан китап нәшрияты, 1974.



УКЫМАГАН—ИЛ БОЗАР, УКЫГАН—ИЛ ТӨЗӘР.



Эш сөймәсне ил сөймәс.

Буй белән түгел, уй белән.


Ир беләге тау җиңә.

Түзгән—тимерне дә өзгән.

Күңел биреп эшләгән эш өлге булыр,
күңел бирми эшләгән эш көлке булыр.



МАТУРЛЫК ТУЙДА КИРӘК,



Кошның матурлыгы төсенә карап,
кешенең матурлыгы эшенә карап.

Эше эшкә охшамый, кулы эштән бушамый.

Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз.

Я уңасың, я туңасың.

Итәгенә ут капса да кузгалмас.

Ир мактаныр, корал эшләр.

Сәләтле сәнәк тотуыннан билгеле.

Уңган кешегә тау түзми.



УҢГАНЛЫК КӨН ДӘ КИРӘК.



Җитез кеше җир астыннан җиз энә табып алыр.

Буласы ир—алты яшендә башмын дияр,
булмас ир—алтмыш яшендә яшьмен дияр.

Ялкауның сапламы озын.

Карама беләккә, кара йөрәккә.

Берәү бар—аз эшли дә үз эшли,
берәү бар—күп эшли дә чүп эшли.

Кулыннан гөл генә таммый.



ЮНЕН ТАПКАН— АЙГА ОЧАР,

Омтылган—зурга омтылыр,
омтылмаган—онытылыр.

Авыр эшкә беләк бар,
кыю эшкә йөрәк бар.

Тәрәзәдән кергән ай яктысына ябышып
күккә менеп булмый.

Аннан ит тә юк, сөт тә юк.

Исәпкә бар, санга юк.





ЮНЬСЕЗ—ҖИРДӘ АБЫНЫП ҮЛӘР.



Булдыксыз—балтадан күрер.

Эшләп үлмиләр, чирләп үләләр.

Ялкауның эше дә таркау.

Авырып торам димә,
иренеп торам диген.

Теле белән күктәге айны йөртә белгән,
кулы белән казандагы майны эретә белмәгән.



ЯЗГЫ БЕРКӨН



Тимерне кызуында сук.

Эшләгән ашый, эшләмәгән башын кашый.

Иртәгегә эшеңне бүген уйлап куй.

Эше барның ашы бар.
Эше юкның ашы юк.

Аяз көнне алма җыя, яңгыр көнне богыл коя.

Калган эшкә кар ява.



ЕЛ ТУЙДЫРА.



Эшләмәсәң эш көне, ни ашарсың кыш көне?

Эшләгән—тешләгән, эшләмәгән—кешнәгән.

Эшләмәгән ашамый, ашамаган яшәми.

Аз кулны ашта күр, күп кулны эштә күр.

Ашаганда колагың селкенсен,
эшләгәндә йөрәгең җилкенсен.



АЛМА ПЕШ, АВЫЗЫМА ТӨШ.

Тырышлык бәхет китерер, ялкаулык ачтан үтерер.

Ялкау бер эш эшли белә,—чалкан ятып мышный белә.

Ялкау әйткән:—Бүген ял итим дә иртәгә ныклап эшләрмен!
Тырыш әйткән:—Бүген тырышып эшлим дә иртәгә ял итәрмен.

Ялкау егет картларга охшар,
җегәрле карт егетләргә охшар.

Җиңелне өмет иткән, тормышы кире киткән.





ЭШЕ КАТЫ, ИКМӘГЕ ТАТЛЫ.



Эшең каты булса, тешеңә йомшак булыр.

Кем эшләми, шул ашамый.

Тирләп эшләсәң, тәмләп ашарсың.

Агач җимеше белән, адәм эше белән.

Эш беткәч, уйнарга ярый.

Эшләнгән эш иргә кот,
яхшы эшләнсә илгә кот.



АГАЙ ОЛЫ, МИН ЗУР,

Гали—Вәлигә, Вәли Галигә ышана.

Син дә мулла, мин дә мулла, атка печән
кем салыр?

Эшем күп, вакытым тар, эт дагалыйсым бар.

Эшле кеше эшен карый, әрәмтамак тешен казый.

Тыйнакның кулы эшләр,
мактанчыкның теле эшләр.





АТКА ПЕЧӘН КЕМ САЛЫР?



Әзергә хәзер.

Аш дигәндә—җан-фәрман, эш дигәндә—
юк дәрман.

Аш янында бүре күк, эш янында шүре күк.


Эшкә булса—алла, башым,
ашка булса—кайда кашыгым?

Комнан аркан ишеп, күлне күккә асып булмый.

Тел белән тегермән тарттырып була,
онлы булып булмый.



ХЕЗМӘТ ИЯСЕ—ХӨРМӘТ ИЯСЕ.



Эш батыры—ил батыры.

Эш күрсәткән ирне ил онытмас.

Данның төбе хөрмәт, хөрмәтнең төбе хезмәт.

Хезмәте барның хөрмәте бар.

Авыр йөкне ат тарта, авыр эшне ир тарта.

Яшьлегең тырыш булса, картлыгың
тыныч булыр.



16 тиен.

Художнигы Тавил Хаҗиәхмәтов

МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАР ӨЧЕН

С(Тат)
Х42

Х $\frac{0761-101}{М132(03)-74}$ 164—73



На общественных началах составил и редактировал
Тагир Нурмухаметов

Художник Тавиль Хазиахметов

ТРУД-БОГАТЫРЬ

Татарские народные пословицы о труде

(на татарском языке)
Җәмәгать эше тәртибендә төзеде һәм редакцияләде
Таһир Нурмөхәммәтов

Художество редакторы Азат Садыйков
Техник редакторы Әнисә Трофимова
Корректоры Сүвәйдә Мөхәммәдьярова

Производствога бирелде 14/VI-1973 ел. Басарга кул куелды 20/XII-1973 ел. Офсет кәгазе № 120 гр., $60 \times 90^1/_8$. Учетн.-изд. табагы 2,29. Якынча басма табагы 2,0. Тираж 17000. Заказ Я-303. Бәясе 16 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. Казан, Бауман ур., 19.

Татарское книжное издательство. Казань, ул. Баумана, 19.

ТАССР Министрлар Советының Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре идарәсенең Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. Казан, Бауман ур., 19.